ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.12.2016 Казан ш. № 7-21/т

Даими ташулар буенча муниципаль маршрутларда Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы, "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлегендә автомобиль транспорты белән пассажирларны һәм багажны даими ташуларга чик дәрәҗәдә максималь тарифлар билгеләү хакында

2015 елның 13 июлендәге "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 220-ФЗ номерлы, 2007 елның 8 ноябрендәге "Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы" 259-ФЗ номерлы Федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1995 елның 7 мартындагы "Бәяләрне (тарифларны) дәүләти җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында" 239 номерлы карарына, 2015 елның 26 декабрендәге "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законны тормышка ашыру хакында" 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шушы карар кушымтасына туры китереп, даими ташулар буенча муниципаль маршрутларда Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы, "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлегендә автомобиль транспорты белән пассажирларны һәм багажны даими ташуларга чик дәрәҗәдә максималь тарифлар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2013 елның 08 февралендәге "Чистай шәһәрендә шәһәр буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирларны һәм багажны ташуларга чик дәрәҗәдә максималь тарифлар билгеләү турында" 7-4/т номерлы карарының 1 пунктын көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
23.12.2016 № 7-21/э карарына
кушымта

## Даими ташулар буенча муниципаль маршрутларда Татарстан Республикасының Чистай муниципаль районы, "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлегендә автомобиль транспорты белән пассажирларны һәм багажны даими ташуларга чик дәрәҗәдә максималь тарифлар

| Транспорт төре | Бер мәртәбә бару һәм бер урынга исәпләнгән багажны алып бару өчен чик дәрәҗәдәге максималь тариф (сум) | | |
|---|---|---|---|
| | билетны транспорт чарасы салонында сатып алганда | юл өчен озак файдаланыла торган билет ярдәмендә түләгәндә | |
| | | 1 мәртәбә барган өчен[1] | 50 һәм аннан күбрәк мәртәбә барган өчен[2] |
| Автобус | 18 | 15 | 10 |

<1> юл өчен билгеләнгән сумма чикләрендә шәһәр буенча юлда йөрү хокукын бирүче, озак файдаланыла торган билет ярдәмендә түләгәндә;

<2> юл өчен күрсәтелгән вакыт чорында шәһәр буенча билгеле күләмдә юлда йөрү хокукын бирүче, озак файдаланыла торган билет ярдәмендә түләгәндә.

Искәрмә. Багажны алып бару бәясен түләү юл бәясен түләүдән аерым гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге